Тәгалә бар кешене дә тигезли һәм бар кешегә дә бирелгәнлектән, ул бер генә кешегә дә икенчесенә караганда азрак бирелмәячәк. Шулай ук үлгәннәргә генә түгел, исәннәргә дә савапны бирергә була.

Дөньяви байлыклар аны башкалар белән бүлешкәндә кими, әмма Аллаһының рәхим-шәфкате кимеми. Әгәр бәз ун хуш исле алмалы капчыкны алып, аны ун кешегә бүлсәк, һәр кешегә берәр алма тиячәк. Әгәр без шул ук алмаларның исен миллион кешегә иснәргә бирсәк, алар бергә дә кимемәячәк, ә аннан алынган тәэсирне барысы да тоячак, һәм берсе дә аерылып калмаячак.

Югарыда китерелгән аңлатманың мәгънәсе шунда: исән кеше өчен дә, шулай ук үлгән кеше өчен дә түләүле Коръән уку өчен кеше ялларга була. Моның әҗерен укучы кеше дә, һәм кем өчен укылган булса, ул да әҗерен алачак, бигрәк тә укучы кеше бу түләүгә мохтаҗ булса һәм ул үзенең гаиләсен тәэмин итә алмаса яки инде бу түләүне изге эшләр өчен файдаланырга уйласа. Әмма, әгәр дә җиңел табыш алу нияте булса, ул очракта Коръән уку өчен түләүне кабул итү тыела. Бер кеше икенчесе урынына намаз укый һәм ураза тота алмый, дигән кодси хәдиснең мәгънәсе түбәндәгедән гыйбарәт: әгәр кем дә булса икенче берәү өчен намаз укыса, бу икенчесе тарафыннан үтәлми калган намазны капламый. Әмма бу үтәлгән намазның, уразаның, олы яки кече хаҗның һәм садаканың әҗерен икенче кешегә бирергә ярамавын һәм аның үзенә бирелгәнне алмавын аңлатмый. Гомумән, сөннәт кешеләре фикеренчә, һәр гадәти изге гамәлдән башлап, намаз уку, ураза тоту белән тәмамлап, һәр изге эшнең әҗерен исән кешегә дә, үлгән кешегә дә бирергә ярый, һәм алар моның әҗерен алачаклар.

Имам Әхмәд белән имам ән-Нәвәви кабер янында Коръән укырга рөхсәт итәләр. Шулай ук күренекле имам-казый Хөсәен мәрхүмнең кабере өстендә түләүле Коръән укырга ярый, дип әйтә. Исламның башлангычында рөхсәт ителмәгән әйберләр бар, әмма соңрак, соңгы буын галимнәре (мөтәәххирүн), шартларга һәм вакыт кушуына бәйле рәвештә, аларның кайберләрен рөхсәт ителгән дип игълан иткәннәр. Боларга дин әһелләренә җитәкчеләр, түрәләр янына барырга, туклану чаралары эзләп башка авылларга бару, дини фәннәрне һәм Коръәнне өйрәтү өчен, имам, мөәзин булып эшләгән өчен акча алу, рөхсәт ителмәгән (мәгсия) белән шөгыльләнү урыннарында җыелучыларга мөселман сәламен бирү керә.

Һәм моңа сәбәп тә бар. Мәсәлән, әгәр дә мөселман бюджеты яки казнасы (бәйт үл-мәл) булмаса, мөәзиннәргә, имамнарга һәм укытучыларга хезмәт хакын каян түләргә соң? Ә хезмәт өчен түләмәү ислам буенча тыелган. Әгәр рөхсәт ителмәгән белән шөгыльләнүчеләргә сәлам бирмәсәң, кешеләр арасында эчке каршылык һәм ызгышлар барлыкка килергә мөмкин. Гомумән алганда, исламдагы хәлне начарайтырга мөмкин булган, югарыда санап үтелгәннәргә охшаш тыюлар бетерелә. Аеруча безнең көннәрдә тәэтергә туры килә торган кимчелекләр күп. Мәсәлән, яшь кеше өйләнергә җыена, һәм ул никах укыту өчен имамга бара. Еш кына яшьләр шаһәдәтнең мәгънәсен белмиләр генә дә түгел, ә аны дөрес итеп кычкырып әйтә дә белмиләр. Бу очракта имамга нишләргә соң? Кияүне никах укымый кире борып җибәрергәме? Ә бу мәсьәләне хәл итәрме? Бу очракта иң максатка ярашлысы тагын да начаррак нәтиҗәдән качу өчен, никахны уку.

**Сәед әфәнде ЧИРКАВИ.**
*("Иман" газетасыннан)*

# Ислам һәм төсләр

Аллаһы Тәгалә дөньяга искиткеч гүзәл төсләр яраткан. Алар безне һәрчак һәм һәр җирдә чолгап алган. Бу – Аллаһыбызның кодрәтен раслаучы бер күренеш. Шунысы игътибарга лаек, төп төсләр дә Аллаһы тарафыннан яратылган күкләр кебек үк җиде, хаҗ кылучылар да Кәгъбә тирәсен нәкъ җиде тапкыр әйләнәләр... Исламда кешеләр яки хайваннарның рәсемен ясау тыелганга, төсләрнең роле тагын да арта төшә.

Ислам күпчелек очракларда яшел төс белән тасвирлана. Бу – яз, табигать яңарышы, азатлык, шатлык, җәннәт төсе. Яшел төс шулай ук үлемсезлек символы да әле, шуңа да аны оҗмах төсе дип атыйлар да. Яшел – табигатьнең тереклек төсе. Ул Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең яраткан төсе дә әле. Бу изге төс кеше гомеренең дәвамлы булып, табигать белән берлектә яшәвен күрсәтә, ә ул инде исламның иң төп кыйммәтләренең берсе булып санала.

Яшел төс җәннәт әһелләренең киемнәре төсе. *«Аларның өсләрендә калын һәм нечкә яшел ефәк киемнәрдер, алар көмеш беләзекләр белән зиннәтләнерләр, Раббылары аларга пакь, татлы эчемлекләр эчертер»* («әл-Инсан» сүрәсе, 21 нче аять). Һәм җәннәт үзенчәлекләре хакында түбәндәге аять тә бар: *«Ул бакчалардагы мөэминнәр яшел түшәкләргә, вә гаҗәп матур паласларга таянучылардыр»* («әл-Рахман» сүрәсе, 76 нчы аять).

Шулай итеп, яшел төс мөселманнарның аңында оҗмах матурлыгы белән тиңләнә. Шуңа күрә бик күпләрнең яраткан төсе ул. Тарихтан билгеле булганча, Пәйгамбәребезнең армиясе яшел, кара һәм ак әләмнәр астында сугышкан. Ислам барлыкка килгән комлы илдә яшел табигать сирәк урында, димәк, яшел төс – бик кадерле нәрсә.

Ислам Идел һәм Урал буена таралгач, руханыйларның киемнәрендә яшел төс өстенлек алган. Бу төс мәчетләрне бизәгәндә, дини китаплардагы орнаментларда, мөселман илләренең әләмнәрендә кулланыла. Әйтергә кирәк, тәре йөртүчеләр гербларында яшел төсне кулланмаска тырышалар. Урта гасырлардагы Европа гербларында да яшел төс



*Матур нурлы йөзләреңне*
*Үбеп-үбеп сыйпадым.*

*Яраткан хатының,*
*Безнең әни, яннарыңда утырды.*
*Бәхил бул, Халит, җанкаем дип,*
*Башларыңнан сыпырды.*

*Җыелдылар барысы да —*
*Оныклар, оныкчалар.*
*Күрсәң иде ничек сине*
*Сагынып еладылар!*

*Күрәлмәдең, әткәй, бәгърем,*
*Барысы да елады.*
*Безнең елап төшкән яшьләр*
*Җиргә төшеп калмады.*

*Алар ап-ак карлар булып*
*Көн озынына яуды.*
*Аннары йомшак мамыктай*
*Кабереңне каплады.*

*Кич җиткәч, без кайтып киттек,*
*Яннарыңнан узганда*
*Куырылды йөрәккәем*
*Сине җиргә күмгәнгә.*

*Йә, Ходаем, бир түземлек*
*Ятим калган бәндәгә.*
*Булсын иде әткәбезнең*
*Урыннары җәннәттә.*

**Халидә ЮСКАЕВА.**
Самара шәһәре.

# Пәйгамбәребез туган көн

*Пәйгамбәребез туган көн*
*Мөбарәк, иң кадерле.*
*Аны олылап мәулид әйтсәк,*
*Бик күп булыр әҗере.*

*Бу көн мөселманнар тарафыннан*
*Зурлап искә алына.*
*Пәйгамбәребез хөрмәтенә*
*Салаватлар әйтелә.*

*Дөнья, Рәсүлебез туган көнне,*
*Кояш чыкканчы яктыра.*
*Хуш киләсең Аллаһы Илчесе,*
*Бар җиһан нурга тула.*

*Мәүлиддин-Нәби кагыйдәләре -*
*Садакалар өләшү.*
*Мөселманнар өчен ляземдер*
*Бу көнне бәйрәм итү.*

*Бик күп маҗаралы хәлләр*
*Бу көнне күзәтелгән.*
*Аллаһы Тәгалә тарафыннан*
*Күпме могҗиза туган!*

*Кешелек дөньясында*
*Күпме серләр ачылган.*
*Пәйгамбәребез үзе һәрчак*
*Ихлас күңелле булган.*

*Мөселманда гадәткә кергән*
*Мәҗлесләр үткәрү.*
*Пәйгамбәребезгә атап*
*Салаватлар җиткерү.*

*Ислам дөньясын үстерүдә*
*Күп көчен сарыф иткән.*
*Мәчет-мәдрәсәләр салдырып,*
*Халыкны дингә керткән.*

*Пәйгамбәребез сабыр, юмарт*
*Булган, изге-шәфкатьле.*
*Гыйбадәт кылыуында булгандыр*
*Гомеренең бәрәкәте.*

*Пәйгамбәребезгә дога кылып*
*Тәүбә-истигъфар итсәк.*
*Гөнаһлардан арынырбыз*
*Әҗәл вакыты җиткәч.*

**Саимә МОРЗАХАНОВА.**
Гали авылы,
Похвистнево районы.

## СОРАГЫЗ-ЖАВАП БИРЕРБЕЗ

**- Сәҗдәгә китү рәвешенә кагылышлы мәсьәлә турында ике төрле караштагы фикер укыган идем. Аларның берсендә сәҗдәгә киткән вакытта идәнгә башта тезне, аннары кулны, ә икенчесендә башта кулны, ә аннары тезне кую турында язылган һәм моңа дәлил итеп хәдис тә китерелгән. Шулай ук анда тезен идәнгә кулдан алдарак тидерүче кеше дөягә охшап кала, диелгән. Бу фикерләрнең кайсы дөрес икән?**

- Имамнар Әбү Хәнифә, әш-Шәфигый һәм Әхмәд мәзһәбендә тезне алданрак кую дөрес дигән фикер яши. Әт-Тирмизи бу фикерне күпчелек галимнәр фикере дип атый: «Галимнәрнең күпчелеге сәҗдәгә киткән вакытта иң элек идәнгә тезләнергә, ә баскан вакытта идәннән беренче чиратта кулны, ә аннары тезне күтәрергә кирәк, дип саный», - ди. Ул үзенең фикерен Ваил ибн Хәҗәрнең: "Мин Аллаһы Илчесенең сәҗдәгә киткән вакытта башта тезләнүен, аннары кулы белән таянуын, ә торган вакытта башта кулын, аннары тезен күтәрүен күрдем", - дигән хәдисе белән дәлилли.

Мәлик, Әл-Авзаий мәзһәбе һәм хәдис белгечләре башта кул белән таянырга кирәк дигән фикердә. Алар үз фикерләрен Әбү Һурайра хәдисе белән дәлиллиләр.

Шәйхүл-ислам бу мәсьәләдә үзенең фәтвалар җыентыгында бик әһәмиятле фикер әйткән: "Намазның үтәлүенә килгәндә, галимнәр аларның икесен дә дөрес дип саныйлар. Намаз укучы башта кулы белән таянырга, ә аннары тезләнергә тели икән — шулай эшләсен, тели икән, башта тезләнсен, ә аннары кулы белән таянсын. Һәр ике очракта да аның намазы дөрес булып санала. Бу хакта галимнәр арасында фикер каршылыгы юк, алар бары тик боларның кайсы яхшырак булуы турында гына бәхәсләшәләр.

*("Дин вә йола" газетасыннан)*